**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 10 май | № 269

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче, 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы, 2015 ел, 26 август, 623 нче, 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы, 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «, наркотик чаралар, психотроп матдәләр әйләнеше һәм аларның прекурсоры белән бәйле» сүзләрен «наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләрне культивацияләү буенча» сүзләренә алмаштырырга;

3.3.6 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалтуын танырга;

3.3.17 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) түбәндәге эшчәнлек төрләрен лицензияләү (лицензияләр бирү һәм аларны яңадан рәсмиләштерү, лицензияләр дубликатларын һәм лицензияләр күчермәләрен бирү, лицензияләрне яңадан рәсмиләштерү турында гариза биргән лицензияләр сораучыларга һәм лицензиатларга карата лицензияне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру, лицензияләрнең гамәлләре тукталу, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары биргән лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару, лицензияләр бирү һәм аларны яңадан рәсмиләштерү турында гаризалар формаларын

раслау, әлеге лицензияләр реестрларыннан хәбәрнамәләр, өземтәләр һәм лицензияләү процессында файдаланыла торган башка документлар формаларын раслау, шулай ук мәнфәгатьле затларга лицензияләү мәсьәләләре турында мәгълүмат бирү, әлеге мәгълүматны, бу мәгълүматтан файдаланучылар сорау җибәрә һәм соратылган мәгълүматны ала алсын өчен электрон почта адресларын күрсәтеп, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының рәсми сайтларында урнаштыруны да кертеп):

а) медицина оешмаларының медицина эшчәнлеге (федераль башкарма хакимият органнары ведомствосындагы медицина оешмаларыннан тыш);

б) фармацевтика эшчәнлеге (федераль башкарма хакимият ведомствосындагы дару чаралары белән күпләп сату итүче оешмалар һәм аптека оешмалары гамәлгә ашыра торган эшчәнлектән тыш);

в) наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше, наркотиклы үсемлекләрне культивацияләү буенча эшчәнлек (Россия Федерациясендә контрольгә алынырга тиеш наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлегенең I, II һәм III исемлекләренә кертелгән наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше буенча эшчәнлек өлешендә, федераль башкарма хакимият ведомствосындагы дару чаралары белән күпләп сату итүче оешмалар һәм аптека оешмалары гамәлгә ашыра торган эшчәнлектән тыш);»;

3.3.36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.36. Балигъ булмаганнарның медицина тикшерүләре, шул исәптән физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә бәйле профилактик медицина тикшерүләре узу, диспансеризация, диспансер күзәтүе, медицина тернәкләндерүе узу, медицина ярдәме алу, шул исәптән белем бирү оешмаларында уку һәм тәрбияләнү чорында, шартларын билгеләү.»;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.3.48 – 3.3.51 пунктлар өстәргә:

«3.3.48. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен федераль законнар нигезендә шартлар тудыру.

3.3.49. Сәламәтлек саклау өлкәсендә гражданнар хокукларын яклау буенча иҗтимагый берләшмәләр катнашында «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 76 статьясындагы 3 өлеш таләпләренә туры килә торган медицина һөнәри коммерциячел булмаган оешмалар (аларның вәкилләрен), медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет булдыру һәм аның турында нигезләмәне раслау.

3.3.50. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз сайтында һәм дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыру.

3.3.51. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз сайтында медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфаты турында пациентларның фикерләрен белдерүнең техник мөмкинлеген тәэмин итү.»;

4.3 пунктның үз көчен югалтуын танырга;

тугызынчы һәм унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дару препаратларын сатып алуга заявкаларны республика ихтыяҗларын исәпкә алып формалаштырырга һәм Гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфа, кан һәм алар янындагы тукымаларның яман шеше, зиһенсез склероз авырулары белән авыручы затларның, әгъзалар һәм (яки) тукымалар трансплантацияләнгән затларның федераль регистрының төбәк сегментын алып баруны гамәлгә ашырырга;

гемофилия, муковисцидоз, гипофизар нанизм, Гоше авыруы, лимфа, кан һәм алар янындагы тукымаларның яман шеше, зиһенсез склероз авырулары белән авыручыларга, әгъзалар һәм (яки) тукымалар трансплантацияләнгән затларга дәвалау өчен республика милкенә тапшырылган дару препаратларын исәпкә алуны һәм тотуны тикшерүдә тотарга;»;

унберенче һәм унҗиденче абзацларның үз көчен югалтуын танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«россия антидопинг оешмасы һәм физик культура һәм спорт өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы белән берлектә спортта допингны булдырмау һәм аның белән көрәш эшен оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләргә.»;

5.2 пунктның уникенче абзацы үз көчен югалтуын танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\269.docx